

Ләмберә районы Кривозерье авыл клубында тулы аншлаг белән «Уйнагыз, гармунчылар!» конкурсы vтте.
Конкурс программасында Ләмберә, Кырви-Кривозерье, Татар Тавласы, Пензятка, Берсеневка, Александровка, Николаевка авылларыннан артистлар катнашты. Кырви авылыннан конкурста кат-кат катнашкан Касыйм Кәримов, Татар Тавласыннан Рафаэль Файзуллов, Берсеневкадан Зыя Максутов һәм башкалар чыгыш ясаганнар. Барлык артистлар тамашачыларнын кочле алкышлары астында чыгышларын ясаганнар һәм гармунчыларга махсус номинацияләрдә истәлекле бvләкләр тапшырылганнар.